МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

12.04.2019 г.Казань № 317-осн

2019 елның 12 февралендәге 79/3-осн номерлы боерык белән расланган Аксубай урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. 2019 елның 12 февралендәге 79/3-осн номерлы боерык белән расланган Аксубай урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 бүлектәге 5 нче таблицада «Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре» графасында «сусаклагычлар һәм башка төр ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү (РФ УК 25, 44 статьялары)» сүзләрен «сусаклагычлар һәм башка төр ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү (РФ УК 25, 44 статьялары, «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 ст. 2 өл. 7 п.)» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 бүлектәге 13 нче пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 13. | Сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү. | Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә сусаклагычлар, башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү тыела (РФ УК 107 ст. 2 өлешендәге 5 пункты). |

2. Әлеге боерык аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр в.б. Ә.Н. Бәдертдинов